ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 43-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, О.М. Воронова, В.В. Вавилов, Д.З. Зарипов, А.И. Зыятдинов, Л.Н. Маврина, А.Р. Нәбиева тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 43-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 213-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
С.М. Захарова,
О.М. Воронова,
В.В. Вавилов,
Д.З. Зарипов,
А.И. Зыятдинов,
Л.Н. Маврина,
А.Р. Нәбиева
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш); 77, № 83, (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 20 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш); 2024 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 116 статьяның 1 өлешендәге 14 пунктка «, шулай ук, җенесен алмаштыруга, шул исәптән башка җенестәге беренчел һәм (яисә) икенчел җенес билгеләрен формалаштыруга юнәлдерелгән дару препаратларын куллануны да кертеп, медицина катнашуы юлы белән җенесне алмаштыру, медицина катнашыннан башка шәхесне таныклый торган документларга әлеге гражданнарның җенесе турында үзгәреш кертү рөхсәт ителгән дәүләтләр гражданнары булган затлар, һәм даими яшәү урыны күрсәтелгән дәүләтләрдә булган гражданлыгы булмаган затлар» сүзләрен өстәргә;

2) 134 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктка «, шулай ук, җенесен алмаштыруга, шул исәптән башка җенестәге беренчел һәм (яисә) икенчел җенес билгеләрен формалаштыруга юнәлдерелгән дару препаратларын куллануны да кертеп, медицина катнашуы юлы белән җенесне алмаштыру, медицина катнашыннан башка шәхесне таныклый торган документларга әлеге гражданнарның җенесе турында үзгәреш кертү рөхсәт ителгән дәүләтләр гражданнары булган затлар, һәм даими

яшәү урыны күрсәтелгән дәүләтләрдә булган гражданлыгы булмаган затлар» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының**
**116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**аңлатма**

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 һәм 146 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 23 ноябрендәге 405-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Гаилә кодексына үзгәрешләр кертелде, аның нигезендә медицина катнашыннан башка җенесне алмаштыру һәм шәхесне таныклый торган документларга әлеге гражданнарның җенесе турында үзгәреш кертү рөхсәт ителгән дәүләтләр гражданнары булган затлар, һәм даими яшәү урыны күрсәтелгән дәүләтләрдә булган гражданлыгы булмаган затлар балаларны уллыкка (кызлыкка) алучылар, шулай ук опекуннар (попечительләр) була алмыйлар.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларын тиешле нигезләмәләр белән тулыландыру тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 116 һәм 134 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.